ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2019 Казан шәһәре № 6-108/тп

"Зәй су каналы" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үзәкләштерелгән су бүлү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен 2020 елга тарифлар билгеләү хакында

"Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Гариза бирүчеләрнең үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яки) су бүлү системаларына тоташтырылган (технологик ялганган) өчен хосусый тәртиптә түләү билгеләнә торган объектларына тоташтырыла торган (ялгана торган) йөкләнеш зурлыгын билгеләү турында " 2017 елның 22 апрелендәге 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Зәй су каналы" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үзәкләштерелгән су бүлү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен шушы карар кушымтасына туры китереп, тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 12.12.2019
№ 6-108/тп карарына кушымта

"Зәй су каналы" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең үзәкләштерелгән су бүлү системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) тарифлар

| № п/п | Күрсәткечнең аталышы | Үлчәү берәмлеге | Тоташуга тарифлар (НДС исәбеннән башка) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырыла торган йөкләнешкә тарифның база ставкасы | тәүлегенә мең сум/куб метр | 1,1420 |
| 2. | Челтәрләр озынлыгына тарифның база ставкасы | мең сум/чм | 4 330,28 |
| 3. | Челтәрләрнең диаметрына карап, тариф дифференциацияләү коэффициенты: | | |
| 3.1. | диаметры 40 мм һәм азрак | - | - |
| 3.2. | диаметры 40 мм югарырак, 70 мм кадәр | - | - |
| 3.3. | диаметры 70 мм югарырак, 100 мм кадәр | - | - |
| 3.4. | диаметры 100 мм югарырак, 150 мм кадәр | - | 0,45 |
| 3.5. | диаметры 150 мм югарырак, 200 мм кадәр | - | 0,52 |
| 3.6. | диаметры 200 мм югарырак, 250 мм кадәр | - | 0,53 |
| 3.7. | диаметры 250 мм һәм аннан да югары | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге